**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

## ПОСТАНОВЛЕНИЕ

## КАРАР

2016 ел, 4 февраль

№ 67

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия гаиләсе өчен торак» программасын тормышка ашыру кысаларында экономияле класслы торак сатып алуга хокуклы гражданнар категорияләре исемлеген, мондый гражданнар исемлекләрен төзү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 15 август, 598 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасы кысаларында «Россия гаиләсе өчен торак» программасын тормышка ашыру буенча төп шартлар һәм чараларның 4 пунктына үзгәреш кертү хакында» 2015 ел, 28 сентябрь, 1023 нче карарын тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының ««Россия гаиләсе өчен торак» программасын тормышка ашыру кысаларында экономияле класслы торак сатып алуга хокуклы гражданнар категорияләре исемлеген, мондый гражданнар исемлекләрен төзү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 15 август, 598 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 23 декабрь, 1008 нче, 2015 ел, 25 май, 371 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган «Россия гаиләсе өчен торак» программасын тормышка ашыру кысаларында экономияле класслы торак сатып алуга хокуклы гражданнар категорияләре исемлегендә:

1 пунктта «40 000 (кырык мең)» сүзләрен «45 000 (кырык биш мең)» сүзләренә, «20 000 (егерме мең)» сүзләрен «30 000 (утыз мең)» сүзләренә, «13 000 (унөч мең)» сүзләрен «25 000 (егерме биш мең)» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктка түбәндәге эчтәлекле 8 һәм 9 пунктчалар өстәргә:

«8) социаль ипотека программасы кысаларында торак сатып алуга хокуклы булганнар:

бюджет тармагы хезмәткәрләре;

социаль ипотеканы финанслауда катнаша торган оешмалар хезмәткәрләре;

каршы тора алмаслык көч шартлары, ягъни гадәттән тыш һәм кайтарып алып булмый торган шартлар, шулай ук табигый характердагы бүтән күренешләр (янгыннар, су басулар һ.б.) нәтиҗәсендә кичектергесез ярдәмгә мохтаҗ гражданнар;

9) Торак төзелешен үстерүгә булышлык күрсәтү федераль фондының экономияле классы торак төзү, шул исәптән мондый торак төзү максатларында аларны комплексы үзләштерү өчен түләүсез вакытлыча файдалануга яки арендага бирелгән җир кишәрлекләрендә төзелгән яки төзелә торган экономияле классы торак сатып алуга хокуклы гражданнар.»;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. «Россия гаиләсе өчен торак» программасын тормышка ашыру кысаларында экономияле классы торак сатып алуга хокуклы гражданнар категорияләре исемлегенең 1 пунктындагы 8 пунктчаның дүртенче абзацында күрсәтелгән гражданнар Татарстан Республикасы территориясендә программаны тормышка ашыру кысаларында экономияле классы торак сатып алуга өстенлекле хокукка ия».

Бу пунктның гамәле әлеге карар көченә кергәнче экономияле классы торак сатып алуга хокуклары булган гражданнарга кагылмый.»;

«экономияле классы торак була,» сүзләреннән соң «яки законнарда каралган бүтән шартнамәләр,» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган «Россия гаиләсе өчен торак» программасын тормышка ашыру кысаларында экономияле классы торак сатып алуга хокуклы гражданнар исемлекләрен төзү тәртибендә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Гражданнар исемлекләрен төзүне Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары) гамәлгә ашыра.

Махсуслашкан оешмалар, махсуслашкан ипотека оешмалары белән шартнамә нигезендә эш итүче, үзләре кабул иткән карарлар нигезендә социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ үз хезмәткәрләре гаиләләрен исәпкә алуны гамәлгә ашыручы һәм реестрын алып баручы Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерү программаларын финанслауда катнашучы милекнең барлык төрендәге оешмалар (алга таба – милекнең барлык төрендәге оешмалар) реестрны махсуслашкан оешмаларга тапшыра.

Махсуслашкан оешмалар үз вәкаләтләре кысаларында:

Татарстан Республикасының шәһәр һәм авыл торак пунктлары территориясендә Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерү программасын тормышка ашыру максатларында җирле үзидарә органнары һәм милекнең барлык төрендәге оешмалар белән үзара бәйләнештә була;

җирле үзидарә органнары, милекнең барлык төрендәге оешмалар гамәлгә ашыра торган исәпкә алу мәгълүматлары нигезендә, инвестиция программасы нигезендә махсуслашкан ипотека оешмаларына бердәм билгеләнгән форма буенча социаль ипотекага мохтаҗ гаиләләр исемлеген җибәрә.»;

7 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Программада катнашу өчен гражданнар, шул исәптән граждан категорияләре исемлегенең 1 пунктындагы 8 пунктчада күрсәтелгән гражданнар теркәлү урыны буенча җирле үзидарә органына түбәндәге документларны бирергә хокуклы:»;

27 пунктның 1 пунктчасында:

«экономияле классны торакны сату-алу шартнамәләре» сүзләреннән соң «законнар нигезендә бүтән шартнамәләр» сүзләрен өстәргә;

«Татарстан Республикасы территориясендә» сүзләрен «Татарстан Республикасында» сүзләренә алмаштырырга;

28, 29 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«28. «Россия гаиләсе өчен торак» программасын тормышка ашыру кысаларында экономияле классны торак сатып алуга хокуклы гражданнар категорияләре исемлегенең 1 пунктындагы 8 пунктчада күрсәтелгән гражданнар әлеге исемлекләргә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларны яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую кагыйдәләрен һәм тәртибен раслау турында» 2005 ел, 15 апрель, 190 нчы карары белән билгеләнгән тәртиптә кертелә.

2. Җирле үзидарә органы һәм махсуслашкан оешмалар ай саен, хисап аеннан соң килүче айның 3енә кадәр әлеге Тәртипкә 4 нче кушымтага ярашлы форма буенча гражданнар исемлеген, мондый исемлеккә кертелгән өстәмәләр һәм үзгәрешләрне күрсәтеп, гражданнар исемлекләренә кертелгән гражданнарның Татарстан Республикасы буенча җыелма реестрын алып баруга вәкаләтле затка тапшыра.»;

әлеге карар белән расланган «Россия гаиләсе өчен торак» программасын тормышка ашыру кысаларында экономияле классны торак сатып алуга хокуклы гражданнар исемлекләренә кертелгән гражданнарның Татарстан Республикасы буенча җыелма реестрын алып бару, мондый гражданнар исемлекләрен төзү һәм мондый реестрдагы мәгълүматларны программа кысаларында йорт салучыларга бирү тәртибендә:

2 пунктның 1 пунктчасында «җирле үзидарә органы» сүзләреннән соң «, милекнең барлык төрендәге оешмалар» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\67.docx